РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Староматакского сельского поселения Алькеевского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Иске Матак авыл жирлеге
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Адрес: 422890, РТ, с. Старые Матаки, ул. Центральная , 4
тел: : 8 (84346) 79-2-12

Адресы: 422890, РТ, Иске Матак авылы, Центральная ур.,4
факс: 8 (84346) 79-2-12

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Иске Матак авылы **КАРАР**

2014 елның 15 апреле 17№

Җәмәгать тыңлауларны үткәрү урынында территорияне (бинаны) тутыруның чик нормаларын билгеләү турында.

2004 елның 19 июнендәге «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» 54-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 25 декабрендәге «Татарстан Республикасында митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар җыелышларын уздыруга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм җәмәгать тыңлаулары чараларында катнашучы гражданнарның, ачык чаралар үткәрү өчен файдаланыла торган объект һәм биналарның иминлеген тәэмин итү, шулай ук җәмәгать тыңлаулары чараларында катнашмаучы затларның хокук һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуларны булдырмау максатларында карар бирәм:

1. Иске Матак авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында хәбәрнамә бирелгәндә чара үткәрү урынында территориянең( бина) тулыландырылуының түбәндәге нормаларын билгеләргә:

   - стационар тамашачы урыны белән җиһазландырылган бинаның иң чик тыгызлыгы - 200 стационар тамашачы урыны, Иске Матак авылы.

   - стационар тамашачы урыны белән җиһазланмаган бинаның иң чик тутырылышы җәмәгать тыңлаулары чарасы үткәрелгән урында 1 квадрат метрга бер кешедән артмый, яки бинаның (корылманың) техник паспорты нигезендә,

   - тротуар, административ биналар янындагы мәйдан һәм мәдәни-күңел ачу учреждениеләрендә - 1 квадрат метрга 3 кешедән артмый.

2. Әлеге карарны Иске Матак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы
Иске Матак авыл җирлеге